ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ТУКТАРОВО-
УРДАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 28 октябре № 24

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Карагай авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Карагай елның 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Карагай авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, ялгыз олы яшәге һәм кереме аз булган гражданнардан, түләүле нигездә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Карагай авылы Тельман урамы буенча вак таш җәю;
- Юлларны карап тоту: Туктар-Урдаласы авылында юлларны кардан чистарту

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Туктар Урдаласы авылында административ бинада -Совет ур., 98, мәдәният йорты бинасында -Совет ур., 103, Карагай авылы, Тельман ур., 31 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
“Туктар-Урдаласы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова